| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» апрель 2015ел № 26

Буа шәһәре

**«2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлектә коррупциягә каршы көрәш планын раслау турында»**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. 2015-2020 елларга Буа муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы көрәш планын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында һәм Буа муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Никифоров

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Буа шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 13 апрелендәге 26 номерлы
карарына кушымта

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча башлыгы ярдәмчесе
____________ З.А. Шәйхаттарова

«____» _____________2015ел

РАСЛЫЙМ
Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе
_______________А.А. Никифоров

«_____» ________________2015ел.

2015-2020 елларга Буа муниципаль районы Башкарма комитетының коррупциягә каршы көрәш планы

| № | Чаралар исеме | Чараларны үтәү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| **1. Коррупциягә каршы торуга юнәлтелгән хокукый һәм оештыру чараларын тәэмин итү** | | | |
| 1.1. | Коррупциягә каршы тору буенча муниципаль хокукый актлар проектларын эшләү | 2015 -2020 ел. | Җитәкче, баш белгеч |
| 1.2. | Муниципаль норматив хокукый актларга һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү | 2015-2020 ел ( даими) | Җитәкче, баш белгеч |
| 1.3. | Тәэмин итүнең административ регламентларын эшләү | 2015-2020 ел | Җитәкче, баш белгеч |
| 1.4. | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына мониторинг ясау, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәр эшләү | 2015 -2020 ел ( даими) | Җитәкче, баш белгеч |
| 1.5. | Муниципаль контроль функцияләрен үтәүнең административ регламентларын куллануга мониторинг үткәрү | 2015-2020 ел | Җитәкче, баш белгеч |
| 1.6. | Коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору | 2015 -2020 ел | Җитәкче, баш белгеч |
| **2. Муниципаль хезмәт үтүгә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәүне контрольдә тоту механизмын камилләштерү** | | | |
| 2.1. | «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә гражданнар муниципаль хезмәткә кергәндә, шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле оешмаларның муниципаль хезмәткәрләрен һәм тыюларны үтәгәндә бирелгән белешмәләрне тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү | 2015 -2020ел. | Җитәкче, баш белгеч |
| 2.2. | Вазыйфалары, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр белән билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең исемлеген үз вакытында тапшырылуын тәэмин итү | 2015 -2020 г. (ел саен 30 апрельгә кадәр) | Баш белгеч |
| 2.3. | Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштыру | 2014-2015 ел (муниципаль вазыйфалар буенча ел саен 30 апрельгә | Баш белгеч |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кадәр) | |
| 2.4. | Җирле үзидарә органнарында коррупция фактлары турында гражданнарның шикаятьләренә һәм мөрәҗәгатьләренә анализ ясау һәм күрсәтелгән фактларны тикшерүне оештыру | 2015-2020 ел | Җитәкче,<br>баш белгеч |
| **3. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә законнар урнаштыру өлкәсендә коррупциягә каршы тору** | | | |
| 3.1. | «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру | 2015-2020 ел | Җитәкче |
| 3.2. | Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда җирле бюджетның бюджет чыгымнары нәтиҗәлелегенә анализ ясау | 2015-2020 ел | Җитәкче,<br>баш белгеч |
| **4. Коррупциягә каршы белем бирү һәм пропаганда оештыру, коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру** | | | |
| 4.1. | Буа муниципаль районының рәсми сайтында Буа шәһәре Башкарма комитетының коррупциягә каршы эшчәнлеген мәгълүмати яктырту | 2015-2020 ел | Баш белгеч |
| **5. Коррупция куркынычы иң югары булган өлкәдә коррупциягә каршы тору** | | | |
| 5.1. | Муниципаль милекне арендага тапшыруга анализ | 2015-2020 ел | Җитәкче |
| 5.2. | Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күчемсез мөлкәттән файдалануны тикшереп тору | 2015-2020 ел | Җитәкче,<br>баш белгеч |